ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН», МЭР ГОРОДА
ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2025 г.Лениногорск № 61

Җир кишәрлегеннән файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары белән, КАРАР БИРӘМ:

1.Кадастр номеры 16:51:012903:1096 булган җир кишәрлегенә һәм кадастр номеры 16:51:013101:1697 булган капиталь төзелеш объектына карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 17 ноябрендә 14:00 сәгатькә билгеләргә.

2. Җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3.Гавами тыңлаулар үткәрү 2025 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш, дип билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

М.Н. Гирфанов

Глухова О.С.
5-28-28